**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**«ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«21» ноябрь 2016 ел № 10/6

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын оештыру һәм алып бару тәртибе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Уставына таянып, норматив хокукый базаны камилләштерү, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы, җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән норматив хокукый актларны унификацияләү һәм системалаштыру, аларның эшчәнлеге турында мәгълүматның ачыклыгын тәэмин итү максатында, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып бару тәртибе турында Нигезләмәне (1 нче кушымта) расларга.
2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып баруга вәкаләтле вәкил итеп Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының нормалаштыру эше өчен җаваплы район Советы Аппаратының юридик бүлеген билгеләргә.
3. Район Советы Аппаратының юридик бүлегенә әлеге карарның 1 пункты белән расланган акт нигезендә:
1) 2016 елның 30 ноябренә кадәр муниципаль норматив хокукый актлар реестрын формалаштырырга һәм аларны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга;
2) муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып баруны һәм аларны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында актуаль хәлдә урнаштыруны тәэмин итәргә;
3) Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен муниципаль норматив хокукый актлар реестрына кертелә торган мәгълүматны билгеләнгән срокларда җибәрүне тәэмин итәргә.
4.Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә эш башкару һәм документлар әйләнеше өчен җаваплы бүлекчәләргә (затларга), бүлекчәләргә яисә әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән затларга

муниципаль норматив хокукый актларга (массакүләм мәгълүмат чараларында, суд актларында, контроль һәм күзәтчелек органнарының җавап бирү актларында, хокукый экспертиза бәяләмәләрендә һ. б.), кергән көнне яисә килеп ирешкән мәгълүматны тапшыруны тәэмин итүне йөкләргә;, күрсәтелгән срокка тапшыру мөмкинлеге булмаган очракта, киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча.

5. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына тәкъдим итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган нигезләмәләргә таянып, җирлекләрнең җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып бару тәртибе турында муниципаль норматив хокукый актларны эшләргә һәм кабул итәргә;

кабул ителгән муниципаль норматив хокукый актлар нигезендә муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып баруны оештырырга һәм аларны тиешле бүлекләрдә муниципаль район рәсми сайтыннан урнаштыруны тәэмин итәргә.

6. Муниципаль район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан җыю һәм муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җаваплы район Советы Аппаратының юридик бүлегенә, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын формалаштыру өчен җирле үзидарә органнарының күрсәтелгән органнары белән үзара хезмәттәшлеген (килешү буенча) оештыру (муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып баруны тәэмин итү һәм алардан белешмәләрне Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына тапшыру максатларында.

7. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм районның рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

9. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык иминлеге буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет рәисе

В.Г. Хаҗиев